# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Яңавыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

28.10.2022 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Яңавыл торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 28 октябрендә 13:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Яңавыл пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм irектән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 800 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Яңа Авыл зиратына койма тоту өчен төзелеш материаллары сатып алу;
2. Урам утларын карап тору, урам яктырткычларын сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм алыштыру, урамнарны яктырту өчен электр товарлары һәм кабель сатып алу;
3. Яңа Авыл торак пункты янәшәсендәге урман буендагы җир кишәрлекләре янәшәсендәге урыннарда юлларга хезмәт күрсәтү (кар чистарту), үлән чабу, янгынга каршы минерализацияләнгән полосаларны сөрү (дизель ягулыгы, запас частьләр сатып алу һәм штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт килешүе буенча хезмәт хакын түләү);
4. Суүткәргеч челтәрләренә хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау, су белән тәэмин итү өчен материаллар һәм электр товарлары сатып алу, скважина өстендә павильон урнаштыру, килешү буенча башкарылган эшләргә түләү;
5. Су чыганагына якын килүче юлларны төзекләндерү (материаллар һәм чишмәдән су үткүрү өчен тораба сатып алу, килешү буенча башкарылган эшләргә түләү);
6. Яңа Авыл авыл территориясенә хезмәт күрсәтүче хезмәткәргә килешү буенча хезмәт хакы түләү;
7. Үлән чабу өчен триммер һәм агачлар кисү өчен бензопычкы сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 198 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 102 кеше, бу 51,5 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 102 катнашучы тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Яңавыл торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип таныргa.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Яңавыл торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 800 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

– Яңа Авыл зиратына койма тоту өчен төзелеш материаллары сатып алу;
– Урам утларын карап тору, электр товарлары сатып алу, урам яктырткычларын урнаштыру һәм алыштыру буенча чаралар;
– Юлларга хезмәт күрсәтү, кар чистарту, үлән чабу, янгынга каршы минеральләштерелгән полосалар сөрү, дизель ягулыгы һәм май алу, хезмәт килешүе буенча штаттан тыш хезмәткәргә-тракторчыга хезмәт хакы түләү;
– Халыкны су белән тәэмин итү, ремонтлау, хезмәт күрсәтү һәм су белән тәэмин итү өчен башка материаллар сатып алу, килешү буенча башкарылган эшләргә түләү;
– Чишмәне ремонтлау һәм төзекләндерү өчен материаллар сатып алу, килешү буенча башкарылган эшләргә түләү;
– Яңавыл авылы территориясенә хезмәт күрсәтүче хезмәткәргә килешү буенча хезмәт хакы түләү;
– Триммер, бензопила сатып алу, үлән чабу һәм агачлар кисү өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыены рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы М.С. Салихов

Совет Новобизякинского сельского поселения
Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002477